**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в Закон Республики Татарстан «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
27 сентября 2024 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 18 марта 2004 года № 15-ЗРТ «О статусе депутата Государственного Совета Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 3 (I часть); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I часть); 2011, № 11 (I часть); 2012, № 7 (I часть); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I часть), № 12 (II часть); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 52 (часть I), № 94 (часть I); 2020, № 57 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 57 (часть I); 2023, № 3 (часть I), № 20 (часть I), № 27 (часть I), № 35 (часть I), № 73 (часть I); 2024, № 44 (часть I) изменение, дополнив его статьей $10^7$ следующего содержания:

«Статья $10^7$. **Ограничение права на выезд из Российской Федерации депутата, осведомленного в сведениях особой важности или совершенно секретных сведениях**

Право на выезд из Российской Федерации депутата, осведомленного в сведениях особой важности или совершенно секретных сведениях в связи с осуществлением депутатских полномочий, может быть временно ограничено.

Решение об ограничении права на выезд из Российской Федерации депутата, осведомленного в сведениях особой важности или совершенно секретных сведениях, принимается Председателем Государственного Совета Республики Татарстан в порядке, определяемом постановлением Государственного Совета Республики Татарстан.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении 10 дней после дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
07 октября 2024 года
№ 75-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 27 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 44 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^{7}$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$10^{7}$ статья. **Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү**

Депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукы вакытлыча чикләнергә мөмкин.

Аеруча мөһим белешмәләрдән яисә тулысынча яшерен белешмәләрдән хәбәрдар булган депутатның Россия Федерациясеннән чыгу хокукын чикләү турында карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарында билгеләнә торган тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан кабул ителә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 07 октябрь
№ 75-ТРЗ